**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 15 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мортыш Баш торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (мотопомпа өчен запас частьләр, материаллар, күрсәткеч такта сатып алу; Мортыш Баш торак пунктындагы янгын сүндерү сулыкларына керү юлында вак таш ташу)төзү, ремонтлау);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мортыш Баш торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары;

Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр; җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу);

5. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мортыш Баш торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар исемлеген төзәтү һәм яңарту; ремонт өчен материаллар сатып алу).

2. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.М.Гыйлфанов